**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы № 128 «10»октября 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 03.12.2021 елның № 40 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмә хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында (25.02.2022 № 46, 17.06.2022 № 59, 02.09.2022 № 62, 24.01.2024 №107,21.06.2024 №123.карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 11 сентябрендәге 1234 номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары нигезендә

Балтач авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 03.12.2021 елның № 40 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмә хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә (25.02.2022 №46, 17.06.2022 №59,02.09.2022 № 62,24.01.2024 №107,21.06.2024 №123.карарлар редакциясендә) 4.7.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

"Профилактик визитны үткәрү вакыты 10 эш көне тәшкил итә, әмма инструменталь тикшерү өчен кирәкле вакытка озайтылырга мөмкин, ләкин ул 4 эш көненнән дә артмаска тиеш. Берничә зат файдалана яисә идарә итә торган объектларда профилактик визит уздырган очракта профилактик визитны уздыру вакыты 10 эш көненә озайтылырга мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов